ГЛАВА
МАТАКСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Улица Колхозная, дом 2,
село Матаки, 422473

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАТАК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Колхоз урамы, 2нче йорт,
Матак авылы, 422473

Тел.: (84375) 3-81-18, 8(9393940522), факс: (84375) 3-81-18, e-mail: Matak.Drz@tatar.ru, моб.89030612959

**Матак авылы**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08 декабрь 2022 ел. № 26

Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Матак авыл
җирлеге территориясендә чүп-чарны,
үләнне, яфракларны һәм башка
калдыкларны яндыру урынына һәм
ысулларына үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 24 октябрендәге 1885 номерлы «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карары нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Матак авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Матак авыл җирлеге территориясендә чүп-чар, үләннәр, яфраклар һәм башка калдыкларны яндыру урыннарын һәм ысулларын билгеләү турында» 2018 елның 30 мартындагы 4 номерлы Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты карарына, 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлегенең торак пунктлары территорияләрендә урнашкан торак пунктларның гомуми кулланылыштагы җирләрендә, шулай ук хосусый йорт биләмәләрендә азык әзерләү өчен махсус бүлеп бирелгән һәм җиһазландырылган урыннардан читтә ачык ут куллану, шулай ук чүп-чар, үлән, яфрак һәм башка калдыклар, материаллар яисә эшләнмәләр яндыру тыела.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

Матак авыл җирлеге башлыгы Шумилов В.И.